КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 август г.Казань № 719

Татарстан Республикасында сәләтле һәм талантлы балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга булышлык күрсәтү өчен конкурс чараларының республика реестры турында

Татарстан Республикасы Президентының «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасында сәләтле һәм талантлы балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга булышлык күрсәтү өчен конкурс чараларының республика реестры;

Татарстан Республикасында сәләтле һәм талантлы балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга булышлык күрсәтү өчен конкурс чараларының республика реестрына үзгәрешләр кертү, шулай ук конкурс чараларының җиңүчеләре һәм призерлары мәгълүматлар базасын формалаштыру һәм алып бару тәртибе.

2. Конкурс чараларының җиңүчеләре һәм призерлары мәгълүматлар базасын формалаштыру һәм алып бару буенча вәкаләтле орган итеп «2.0 Казан талантлар ачык университеты» автоном коммерциячел булмаган оешмасын билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин